0+

РӘШИТ БӘШӘР

# Качышлы уйный тургай



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Б90

Рәссамы *Рөстәм Хәбибуллин*

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Татарстан китап нәшрияты
Татарское книжное издательство
www.tatkniga.ru

**Бәшәр, Р. Г.**

Б90 Качышлы уйный тургай : балалар өчен шигырьләр, табышмаклар / Рәшит Бәшәр ; [рәссамы Рөстәм Хәбибуллин]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2019. – 31 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-03789-1

Шагыйрь үзенең нәни дусларын серләр тулы шигърият иленә кунакка дәшә. Ул илдә сихри төсләр балкышы, тылсымлы авазлар яңгырашы, сурәтле хәрәкәт – һәммәсе дә бар.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03789-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2019
© Бәшәров Р. Г., 2019

# Эчтәлек


Туган көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Күбәләкле йолдыз . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Туганнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Кызчык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Чыклы куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Төнге ау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Кунак мәче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Шомырт исе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Баллы бармак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Җиләкле җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Кар бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Безнең гаилә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Эссе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Рәсем ясыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Тузганак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Яңа күлмәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Чират . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Кичке җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Футбол уйныйм . . . . . . . . . . . . . . . 13
Сеңлем туды . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Качышлы уйный тургай . . . . . . . . . . . 14
Әнием сөлгесе . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Хәйләкәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Үзем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Челләдән соң . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Балкыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Муйнак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Мультфильм . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Ал эшләпә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Әлли-бәлли-бәү . . . . . . . . . . . . . . . 18
Әниемне йоклатам . . . . . . . . . . . . . . 18
Яңа ай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Йолдызлы яңгыр . . . . . . . . . . . . . . 19
Күчтәнәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Мыраубикә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Сискәнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Чыклы алан . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Юл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Чигү чиктек . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Беренче кар . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Суык җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Тын иртә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Чыпчык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Көймә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Табышмак әйтәм . . . . . . . . . . . . . . 27

## Туган көн

Чылтырый да чылтырый
Телефон.
«Тизрәк үс, тизрәк үс!» – ди
Теллефон.
Минем өчен ул бүген –
Гөллефон,
Шоколадлы һәм тортлы
Тәмлефон.
Һәммәсе дә котлыйлар –
Ямьлефон!





## Күбәләкле йолдыз

Йолдызлар нигә биек?
Ә җир нигә түгәрәк?
Очып менала микән
Йолдызларга күбәләк?
Менәдер, ник менмәсен,
Менә ич мендем, дидер.
Һавада йолдыз түгел,
Күбәләк җемелдидер.

## Туганнар

Без өчәү:
Дамир, Сабир,
Мин – Әмир.
Алтынчы яшь
Дамирга,
Ике яшь тик
Сабирга.
Җиләк сузам
Дамирга,
Дамир бирә
Сабирга.
Сабир энем
Очына:
Сусыл җиләк –
Учында.

